| | |
|---|---|
| СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «НОВОЧЕРШИЛИНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» ЛЕНИНОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «ЯНА ЧЫРШЫЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ |

---

РЕШЕНИЕ　　　　　　　　　　　　КАРАР

2025 елның 29 апреле　　　　　　　　　　　　№ 12

**Лениногорск муниципаль районына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча авыл җирлеге вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруны тапшыру турында**

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 2025 елның 23 апрелендәге 1-31/6492 номерлы авыл һәм шәһәр җирлекләре вәкаләтләрен тапшыру турындагы хатын карап, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының « Яңа Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы белән Яңа Чыршылы авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1.Лениногорск муниципаль районының вәкиллекле органына исәпкә алу буенча вәкаләтләр кабул итү, шулай ук муниципаль мөлкәт һәм авыл җирлегенең җир ресурслары белән эш итү турындагы тәкъдимне карауны тәкъдим итәргә.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Советына карауга җибәрергә.

3.Әлеге карарны түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә: Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Яңа Чыршылы поселогы, Заречная ур.,25 йорт, Үзәк ур.,12А йорт, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (https://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru)бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплыгымда калдырам.

«Яңа Чыршылы авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Совет рәисе　　　　　　　　　　　　Р.Ә.Мөхәмәтшина

ИНН 1625000670
КПП 164901001